DOI: 10.26907/2311-2042-2024-22-1-193-198

# THE PIONEERS, HISTORICAL PAGES AND GOLDEN PILLARS OF THE SILVER SCREEN

**Vasil Zagitovich Garifullin,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation,
vasilgarifullin@mail.ru.

The article provides a review of the monograph "Tatarstan televideniese: telefottan alyp tsifly tehnologiyalerge" (Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies) by Kazan Federal University Professor R. Dautova and KNRTU-KAI Researcher M. Shleimovich. The monograph, dedicated to the history of Tatarstan television, conducts a detailed analysis of the television in terms of its creative and technological development. The review notes that the book widely covers the activities of the people who made a huge contribution to the emergence of television, but whose names are still little known.

**Key words**: Tatars, Tatarstan television, history, R. Dautova, M. Shleimovich

Tatarstan television celebrates its 65$^{th}$ anniversary in 2024. In the history of Tatarstan, November 1, 1959 is marked as the day when the Kazan Television studio was opened. Starting from this day, television began to penetrate into the lives of Tatarstan residents, into the daily life of the Tatar people. Even now I can remember that when we were children, we used to read books from the village library, passing them from hand to hand, until they looked completely worn out. We also subscribed to ten to fifteen different newspapers and magazines. When TV came into our lives, a very fun life began. As soon as we brought home a newspaper with a TV time table, we carefully studied it, noting the programs, interesting films and cartoons that would be shown next week, and underlined them. After that, we eagerly awaited for the program to start, holding this time table in our hands. Very few programs for children in the Tatar language were like a real treat. It was with great interest that adults watched concerts, television performances and weekly almanacs created at the Kazan television studio.

Unfortunately, little studied remain the origins of our television, which has a fairly rich history, the stages of its development and its legendary personalities. Professor of Kazan Federal University Rezeda Dautova, Doctor of History, is one of the authors who has been actively working to fill in the gaps of the television history. Most recently, her voluminous monographic work on the history of Tatarstan television, entitled "Tatarstan televideniese: telefottan alyp tsifly tehnologiyalerge" (Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies), was published in the form of a book. Her co-author is a researcher, a technical expert, the head of the department at KNRTU-KAI Mikhail Shleimovich.

Indeed, the book clearly shows two planes of the television development in Tatarstan: its creative and technical-technological planes. The emergence and development of television, as a form of creative art and a branch of culture, is primarily associated with the development of exact sciences and technical discoveries. Naturally, in this regard, the first chapter of the book describes the technological achievements that made the creation of television possible. To tell the truth, no one can clearly answer the question of who invented television. Because the television signal we watch today is not the achievement of just one person. Speaking about the origin of television, first of all, we mention the Russian physicist Boris Rosing who, at the beginning of the 20th century, invented a tube working with electron beams, and Vladimir Zvorykin was the inventor of the first television set working with this kind of tube; we remember the German scientist Paul Nippkow who invented a device that switches images using a mechanical disk. But few people know that the Kazan engineer Alexander Polumordvinov was involved in the invention of color television. While working at the United Kazan Industrial School as a teacher of mechanical sciences and drawing, in 1899 Polumordvinov applied for a patent for a color television system. At the beginning of 1900, at the first electrical engineering congress in St. Petersburg, Alexander Polumordvinov made a report on his invention. A. Popov, B. Rosing and other outstanding scientists expressed their solidarity with him and offered their help. In 1903, it was Polumordvinov who first proposed combining the transmission of

color and sound; at that time it was akin to a revolution. The War Ministry also got interested in the scientist's inventions. The military goals were clear: at that time, it was important to be able to quickly present a clear existing situation in military conditions. In 1900, Polumordvinov received a subsidy of 2,000 rubles from the War Ministry. In 1903, the inventor patented a device for simultaneous transmission of image and sound.

The book "Tatarstan televideniese: telefottan alyp tsifly tehnologiyalerge" (Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies) gives a well-deserved high assessment of Alexander Polumordvinov's work. The authors of the book call this scientist the pioneer of Tatarstan television and accurately describe the essence of Polumordvinov's discovery.

Unfortunately, the scientist's fate, like that of many others, was tragic: he was forced to fight bureaucracy and raise money to launch his invention, which greatly undermined his health. In the end, he had to sell his patent to the English scientist John Baird. After some improvements, in 1925, Baird put the long-distance color image transmission system through laboratory tests and in 1928, he organized the first public display. As a result, it was he who went down in history as the inventor of color television. Without the devices of Polumordvinov and other inventors there would be no electronic television.

Electronic television, which Zvorykin proposed in 1923, turned out to be simpler and cheaper than photomechanical television, and the name of the Kazan scientist Polumordvinov was completely forgotten.

The author of the second great discovery in the field of television was also our fellow countryman. Born in 1892 and raised in the village of Russkaya Aisha near Kazan, Alexander Polyakov invented the video recorder in 1948. However, as this discovery was also made abroad, in our country his name is known to a small circle of people. The new book on the history of television provides some interesting information about this fact.

Obviously, the book analyzes in detail the history of local television programs, created in Kazan by a team of radio amateurs. The book mentions that thanks to the efforts of these amateurs, the first television sets were assembled in our capital as early as in 1937, moreover, in the early 1950s, "Zvezda" brand televisions were assembled at one of the Kazan factories. During the same period, a television center was created in Kazan and its experimental programs were first broadcast in 1955 – these are the facts that deserve our attention.

The Kazan television studio, which began working professionally in 1959, introduced its viewers to examples of high art from the very first days. To begin with, music programs prepared in Moscow and various films were shown on air. Later, the studio began broadcasting its own programs. The development of national television began with information programs. In 1960, the first portable television station was brought to the Kazan television studio and made it possible for the viewers to see live events on television screens. On September 27, 1960, the first television report was broadcast.

From its first days, the Kazan television studio employed real professionals, who had won a tough competition to work here, they left their mark on the achievements in the field of literature and art. The famous directors, Gali Khusaenov, Idmas Utyaganov and Akhtam Zaripov, starting from the 1960s, created immortal television plays, television and documentary films, television concerts, feature films and interesting programs that are included in the golden fund of our television. The famous cameramen, Toivo Kaljurand, Eduard Utyaganov, Stanislav Yarosh, Yuri Gvozd, Iskander Shamsetdinov and Vitaly Mironov, the brilliant presenters like Irkya Sakaeva, Abdulla Dubin, Galina Zimenkova, Amina Safiullina, Rousstem Nabiullin, Elmira Khammatova and Nailya Nogmanova worked here. All of them deserve to be called the golden pillars of our silver screen. It is next to impossible to enumerate and list the editors and journalists who worked here at different times. Besides simply mentioning them, the book gives a worthy assessment of their dedicated work.

The book analyzes stages of the television development in connection with the socio-political situation in the country. Until the 1980s, the duration of Kazan television studio programs was very limited. The programs were mainly broadcast in the evening. The 1990s, which brought about dramatic changes, began a new stage in the development of television in Tatarstan. It was during these years that the volume of national programs on Tatarstan television increased. The appearance of leading journalists on air was a big innovation. Many new types of programs appeared.

In the nineties, several more new television channels were opened in Tatarstan. It was a period of intense rivalry on television. The year of 2002 went down in history as the year of the television formation when the radio company "Tatarstan – Novyi Vek" ("Tatarstan – New Century") ("TNV") was created on the basis of the Kazan television

studio. At the same time, the Tatarstan State Television and Radio Company continued its activities. In 2012, the first satellite TV channel "TNV-Planeta" began broadcasting to all regions of the Russian Federation and other countries. Later, the "Shayan-TV" channel got its independence.

Thus, R. Dautova and M. Shleimovich's book "Tatarstan televideniese: telefottan alyp tsifly tehnologiyalerge" (Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies) describes all stages of the republican television development in detail. It also examines the prospects for its future development, using special formulas and digital data to prove the advantages of the signal transmission through digital technologies at a high scientific level. The fact that the book contains official documents, related to the development of Tatarstan television, in the form of separate appendices increases the value of the book.

It should be noted that for one of the authors of this book, scientist Rezeda Dautova, known as a theorist and practitioner of journalism both in the republic and in the country, television is an especially close sphere. Her mother, Liliya Nigmatova, began her professional career at the Kazan television studio in her youth; later she became a senior director responsible for broadcasting the most important and complex programs. Reseda followed in her footsteps; as early as in school she was drawn to television actively participating in children's programs. The choice of the Journalism Department of Kazan State University after leaving school was probably due to her love for television. However, life made its own adjustments to her plans and dreams. In her student years, Reseda began working for a university newspaper, and after receiving a diploma in journalism, she was invited to work for the newspaper "Vechernyaya Kazan" ("The Evening Kazan"), which was considered the most daring and influential publication in the Republic in the 1990s. Still, her connection with television has not broken: having gained some practical experience, she returned to the University and completed a postgraduate course. Under the guidance of the famous scientist Indus Tagirov, the young researcher began to study the history of Tatarstan television and in 2004, she presented her Ph.D. thesis on this topic. Her further scientific research was also related to the stages of our television development. As a result of her work, Rezeda Dautova was entrusted with the training of television personnel at the University: she became both the first head of the Department of Television Programs and Television Production, which opened at KFU in 2013, and one of the founders of undergraduate and graduate programs in the field of "Television" in Russia.

R. Dautova's book "Tatarstan televideniese: telefottan alyp tsifly tehnologiyalerge" (Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies), written in collaboration with scientist M. Shleimovich, an expert in television technology, should be considered a major event in the scientific career of both scholars. It should be emphasized that it will go down in history as the first voluminous scientific publication covering the history of our television in detail.

**References**

1. Dautova, R. V., Shleimovich, M. P. (2023). *Televidenie Tatarstana: ot telefota do tsifrovykh tekhnologii* [Television of Tatarstan: From Telephot to Digital Technologies]. Kollektivnaya monografiya. Ed. O. G. Morozov. 371 p. Kazan, izd. KNRTU-KAI. (In Russian)

---

# ЗӘҢГӘР ЭКРАННЫҢ ЧИШМӘ БАШЫ, ТАРИХИ СӘХИФӘЛӘРЕ ҺӘМ АЛТЫН БАГАНАЛАРЫ

**Васил Заһит улы Гарифуллин,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
vasilgarifullin@mail.ru

Мәкаләдә Казан федераль университеты профессоры Р. В. Даутова һәм КНИТУ-КАИ галиме М. П. Шлеймовичның «Татарстан телевидениесе: телефоттан алып цифрлы технологияләргә» дигән монографиясенә күзәтү ясала. Татарстан телевидениесе тарихына багышланган монографиядә телевидениенең иҗади һәм технологик яссылыклардагы үсеше эзлекле рәвештә җентекле анализлана. Шулай ук китапта телевидение барлыкка килүгә зур өлеш керткән, ләкин моңа кадәр исемнәре аз билгеле булган шәхесләрнең эшчәнлеге дә киң яктыртылган булуы әйтелә.

**Төп төшенчәләр**: татарлар, Татарстан телевидениесе, тарих, Р. В. Даутова, М. П. Шлеймович

Татарстан телевидениесе 2024 елда үзенең 65 еллык юбилеен бәйрәм итә. 1959 елның 1 ноябре Татарстан тарихына Казан телевидение студиясе эшли башлаган көн буларак теркәлгән. Шул көннән башлап телевидение татарстанлылар тормышына, татар халкының көндәлек яшәешенә көннән-көн киңрәк үтеп керә башлый. Әле дә хәтердә, без бала чакта авыл китапханәсендәге китапларны тәмам тузып-таушалып беткәнче, кулдан-кулга йөртеп укый идек. Өстәвенә өйгә ун-унбишәр төрле газета-журнал алдырабыз. Тормышыбызга телевизор килеп кергәч, бөтенләй күңелле тормыш башланды. Өйгә атналык телетапшырулар программасы игълан ителгән газета килеп төшү белән, аны энәсеннән-җебенә кадәр өйрәнеп, киләсе атнада булачак тапшыруларның, маҗаралы фильм һәм мультфильмнарны барлап чыгабыз, асларына сыза-сыза билгеләп куябыз. Аннары кулга шул программаны тотып, түземсезлек белән тапшыру башланганын көтеп утырабыз. Балалар өчен әллә нигә бер була торган татарча тапшырулар – үзе зур бер бәйрәм кебек иде. Олылар исә Казан телестудиясендә әзерләнгән концертларны, телевизион спектакльләрне, атналык альманахларны бик яратып карыйлар иде.

Кызганычка, гаять бай тарихлы телевидениебезнең барлыкка килүе дә, үсеш этаплары да, аның белән бәйле легендар шәхесләр дә бүгенге көнгә кадәр бик аз өйрәнелгән. Әлеге тарихның ак битләрен барлау һәм тулыландыру юлында соңгы елларда актив эшләгән авторларның берсе – тарих фәннәре докторы, Казан федераль университеты профессоры Резеда Вагиз кызы Даутова. Әле күптән түгел генә аның Татарстан телевидениесе тарихына багышлап язылган зур күләмле «Татарстан телевидениесе: телефоттан алып цифрлы технологияләргә» (Телевидение Татарстана: от телефота до цифровых технологий) дип аталган монографик хезмәте китап буларак басылып чыкты. Китапны язуда тагын бер авторның, техник яктан коралланган галимнең дә катнашуы бик табигый. Бу – КНИТУ-КАИ уку йортының кафедра мөдире Михаил Петрович Шлеймович.

Чынлап та, китапта Татарстанда телевидение үсешенең ике яссылыгын бик ачык күзәтеп була: иҗади һәм техник-технологик яссылыкларны. Телевидениенең иҗат төре, мәдәният һәм сәнгать тармагы буларак барлыкка килүе һәм алга китеше, беренче чиратта, төгәл фәннәрнең үсеше һәм техник ачышлар белән бәйле. Табигый, бу нисбәттән китапның беренче бүлегендә телевидениене барлыкка китергән техника казанышлары турында сүз бара. Дөресен генә әйткәндә, телевидениене кем уйлап тапкан дигән сорауга дөрес җавапны бирәү дә өздереп кенә әйтә алмый. Чөнки бүген без карый торган телевизион сигнал – бер генә кешенең ачыш-казанышы нәтиҗәсе түгел. Телевидение барлыкка килүе турында сөйләгәндә, беренче чиратта, XX гасыр башында ук электрон нурлар белән эшли торган трубканы уйлап тапкан Россия физигы Борис Розинг һәм шундый трубкалы беренче телевизорны уйлап чыгарган Владимир Зворыкинны телгә алалар, механик диск аша сурәтләр күчерә торган җайланма ясаган немец галиме Пауль Нипков турында әйтәләр. Ә менә Казан инженеры Александр Полумордвиновның төсле телевидение уйлап табуга катнашы барлыгын бик аз кеше белә. Казан берләшкән сәнәгать училищесында механика фәннәре һәм сызым укытучысы булып эшләгән чорында, 1899 елда Полумордвинов төсле телевизион системаны патентлаштыруга гариза бирә. 1900 ел башында Петербургта узган беренче электротехника съездында Александр Полумордвинов үзенең ачышы турында доклад ясый. А. Попов, Б. Розинг һәм башка күренекле галимнәр аңа теләктәшлек белдерә, ярдәм кулы suza. 1903 елда нәкъ менә Полумордвинов беренче булып төс һәм тавыш тапшыруны берләштерергә тәкъдим итә, ул вакытта бу революция була. Галимнең эшләнмәләре белән хәрби министрлык та кызыксына. Хәрбиләрнең максатлары аңлашыла: ул вакытта мәгълүматны тиз тапшыру мөмкинлеге сугыш шартларында бик файдалы булыр иде. 1900 елда Полумордвинов хәрби министрлыктан 2000 сум субсидия ала. 1903 елда уйлап табучы бер үк вакытта сурәт һәм тавыш тапшыру өчен җайланманы патентлый.

«Татарстан телевидениесе: телефоттан алып цифрлы технологияләргә» китабында Александр Аполлонович эшчәнлегенә тиешле югары бәя бирелгән. Татарстанда телевидение үсешенең чишмә башы дип китап авторлары нәкъ менә әлеге галимне атыйлар һәм Полумордвинов ачышының асылын ачык итеп күрсәтеп бирәләр.

Кызганычка каршы, галимнең язмышы башка бик күпләрнеке кебек фаҗигале була: ул

бюрократлар белән көрәшеп, үз эшләнмәсен гамәлгә куяр өчен өчен акча җыярга мәҗбүр булып, сәламәтлеген нык какшата. Үзенең патентын инглиз галиме Джон Бэрдка сатарга мәҗбүр була. Кайбер камилләштерүләрдән соң, 1925 елда Бэрд төсле сурәтләрне еракка тапшыру системасын лаборатория сынаулары аша уздыра, ә 1928 елда беренче җәмәгать каравын оештыра. Нәтиҗәдә тарихка нәкъ менә ул төсле телевидение уйлап табучы буларак керә. Әгәр Полумордвинов һәм башка уйлап табучылар эшләнмәләре булмаса, электрон телевидение дә булмас иде.

1923 елда Зворыкин тәкъдим иткән электрон телевидение фотомеханик телевидениегә караганда гадирәк һәм арзанрак булып чыга һәм Казан галиме Полумордвиновның исеме тәмам онытыла.

Телевидение өлкәсендәге икенче бер зур ачышның да авторы безнең якташыбыз икән. 1892 елда Казан янындагы Рус Әйшәсе авылында туып үскән Александр Матвеевич Поляков 1948 елда видеомагнитофон уйлап тапкан. Ләкин ачышын чит илдә ясаганлыгы аркасында, аның исеме дә безнең илдә бик азларга гына билгеле була. Телевидение тарихына багышланган яңа китапта бу хакта гаять кызыклы мәгълүматлар бар.

Әлбәттә, китапта шулай ук Казанда радиосөючеләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә туган җирле телевизион тапшырулар тарихы җентекле анализлана. Үзешчәннәр тырышлыгы белән мәркәзебездә беренче телевизорларның 1937 елда ук җыелуы, ә инде 50 нче еллар башыннан Казан заводларының берсендә «Звезда» маркалы телевизорлар ясала башлавы искә алына. Шул ук чорда Казанда телевизион үзәк төзелүе һәм аның эксперимент рәвешендәге тапшырулары 1955 елда чыга башлавы да – игътибарга лаеклы фактлар.

1959 елдан профессиональ рәвештә эшли башлаган Казан телевидение студиясе беренче көннәреннән тамашачыларны югары сәнгать үрнәкләре белән таныштыра. Башта эфирда Мәскәүдә әзерләнгән музыкаль программалар һәм төрле фильмнар күрсәтелә. Соңрак студия үз тапшыруларын гамәлгә куя башлый. Милли телевидение үсеше мәгълүмати тапшыру барлыкка килүдән башлана. 1960 елда Казан телевидение студиясенә беренче күчмә телевизион станция кайта һәм ул телеэкранда вакыйгаларның тере шаһитларын күрергә мөмкинлек тудыра. 1960 елның 27 нче сентябренә беренче телевизион репортаж эфирга чыга.

Казан телестудиясе барлыкка килүнең беренче көннәреннән үк биредә зур конкурс буенча сайлап алынган чын профессионаллар, әдәбиятсәнгать өлкәсендә тирән эз калдырган зур шәхесләр эшли. Гали Хөсәенов, Идмас Үтәгәнов, Әхтәм Зарипов кебек танылган режиссёрлар 60 нчы еллардан башлап телевидениенең җуелмас фондына кергән үлемсез телеспектакльләр, телевизион һәм документаль фильмнар, фильм-концертлар, кызыклы тапшырулар иҗат итә. Биредә Тойво Кальюранд, Эдуард Үтәгәнов, Станислав Ярош, Юрий Гвоздь, Искәндәр Шәмсетдинов, Виталий Миронов кебек танылган операторлар, Иркә Сакаева, Абдулла Дубин, Галина Зименкова, Әминә Сафиуллина, Рөстәм Нәбиуллин, Эльмира Хамматова, Наилә Ногманова кебек оста дикторлар иҗат итә. Алар барысы да зәңгәр экраныбызның алтын баганалары дип аталырга хаклы. Ә инде биредә төрле елларда эшләгән редактор-журналистларның исемнәрен санап-барлап чыгу гына да мөмкин түгелдер кебек. Китапта аларның һәркайсы искә алына, алай гына да түгел, аларның эшчәнлекләренә тиешле гадел бәя бирелә.

Китапта телевидение үсешенең аерым этаплары илдәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять белән бәйләп анализлана. 1980 елларга кадәр Казан телевидение студиясе программаларының вакыты нык чикләнгән була. Тапшырулар күбесенчә кичке вакытта эфирга чыга. Зур үзгәрешләр алып килгән 1990 еллар Татарстанда телевидение үсешендә яңа бер этапны башлап җибәрә. Нәкъ шушы елларда Татарстан телевидениесендә милли тапшыруларның күләме арттырыла. Эфирга зур яңалык булып алып баручы-журналистлар килеп керә. Күп кенә яңа тип тапшырулар барлыкка килә.

Туксанынчы еллар Татарстанда тагын берничә телевизион канал оешу чоры да булды. Телевизион эфирда көчле көндәшлек чоры башланып китте. 2002 ел Казан телевидение студиясе базасында «Татарстан – яңа гасыр» («ТНВ») телерадиокомпаниясе барлыкка килүе белән тарихка керде. Бер үк вакытта Татарстан дәүләт телерадиокомпаниясе үз эшчәнлеген дәвам итте. 2012 елда Россия Федерациясенең барлык регионнары һәм дөнья илләренә эшли торган беренче спутник телеканалы «ТНВ-Планета» үз тапшыруларын эфирга чыгара башлады. Соңрак «Шаян-ТВ» телеканалы мөстәкыйльлек алды.

Шулай итеп, Р. В. Даутова һәм М. П. Шлеймовичның «Татарстан телевидениесе: телефоттан алып цифрлы технологияләргә» китабында

республикабызда телевидение үсешенең барлык этаплары җентекле күрсәтеп бирелгән. Өстәвенә биредә телевидение үсешенең киләчәк перспективалары күзаллана, цифрлы технологияләр аша сигнал тапшыруның өстенлекле яклары махсус формулалар һәм саннар ярдәмендә югары фәнни дәрәҗәдә исбатлап бирелә. Китапта аерым кушымталар рәвешендә Татарстанда телевидение үсеше белән бәйле рәсми документларның китерелүе аның кыйммәтен тагын да арттыра.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп китү урынлы булыр: әлеге китап авторларының берсе – журналистика теоретигы һәм практигы буларак республикабызда да, илдә дә шактый ук танылу алган галимә Резеда Даутова өчен телевидение – аеруча якын өлкә. Әнисе Лилия Нигъмәтова яшьли Казан телевидение студиясенә эшкә килгән, соңрак иң җаваплы һәм катлаулы тапшыруларны эфирга чыгара башлаган өлкән режиссёр булып җитешә. Аңа ияреп, Резеда да мәктәп елларыннан ук телевидениегә тартылып үсә, балалар тапшыруларында актив катнаша. Мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керүе дә телевидениегә мәхәббәте белән бәйле булгандыр. Ләкин тормыш максат-хыялларга үз төзәтмәләрен кертә. Студент елларыннан ук Резеда университет газетасында эшли башлый, журналист дипломы алгач исә аны узган гасырның туксанынчы елларында республикабызның иң кыю һәм абруйлы басмаларыннан саналган «Вечерняя Казань» газетасына эшкә чакыралар. Шулай да телевидение белән булган бәйләнешлар өзелми: практик тәҗрибә туплап, үзе укыган университетка аспирант буларак әйләнеп кайткан яшь галимә атаклы галимебез Индус Таһиров җитәкчелегендә Татарстан телевидениесе тарихын өйрәнергә керешә һәм 2004 елда шушы темага кандидатлык диссертациясе яклый. Галимәнең моннан соңгы фәнни эзләнүләре дә телевидениебезнең үсеш сәхифәләре белән тыгыз бәйле. Шуның нәтиҗәсендә университетта телевидение кадрлары әзерләү бурычы аңа йөкләнә: 2013 елда КФУда ачылган телетапшырулар һәм телепроизводство кафедрасының беренче мөдире дә, Россиядә беренчеләрдән булып «Телевидение» юнәлеше буенча бакалавриат һәм магистратура программаларын гамәлгә куючы да Резеда Вагиз кызы Даутова булды.

Ә инде Р. В. Даутованың телевизион технологияләр өлкәсен өйрәнүче галим М. П. Шлеймович белән фәнни тандемда иҗат ителгән «Татарстан телевидениесе: телефоттан алып цифрлы технологияләргә» китабын ике галимнең дә фәнни эшчәнлегендәге зур этап вакыйгасы дип кабул итәргә һәм телевидениебез тарихын җентекле яктырткан беренче күләмле фәнни хезмәт буларак, тарихка кереп калачагын ассызыкларга кирәк.

**Әдәбият**

1. *Даутова Р. В., Шлеймович М. П.* Телевидение Татарстана: от телефота до цифровых технологий. Коллективная монография / Под ред. О. Г. Морозова. Казань: издательство КНИТУ-КАИ, 2023. 371 б.

---

# У ИСТОКОВ ТЕЛЕВИДЕНИЯ, СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ И ЗОЛОТЫЕ СТОЛПЫ

**Васил Загитович Гарифуллин,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казан, ул.Кремлевская, д. 18
vasilgarifullin@mail.ru

В статье представлена рецензия на монографию профессора Казанского федерального университета Р. Даутовой и научного сотрудника КНИТУ-КАИ М. Шлеймовича «Телевидение Татарстана: от телефото к цифровым технологиям». В монографии, посвященной истории татарстанского телевещания, проводится подробный анализ телевидения с точки зрения его творческого и технологического развития. В рецензии отмечается, что в книге широко освещается деятельность людей, внесших огромный вклад в становление телевидения, но чьи имена до сих пор малоизвестны.

**Ключевые слова**: татары, татарское телевидение, история, Р. В. Даутова, М. П. Шлеймович